| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2022 Баулы шәһәре №81

«Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 73 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 2 августындагы 751 номерлы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» карарының 1 нче кушымтасына һәм 2022 елның 17 сентябрендәге «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы таралмый торган бюджет даирәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен күтәрү һәм «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таратылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында”гы 1013 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турындагы” 2022 елның 27 августындагы 916 номерлы карарлары нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 73 номерлы карарына (2018 елның 28 сентябрендәге 90 номерлы карар, 2020 елның 28 августындагы 140 номерлы карар, 2022 елның 22 февралендәге 55 номерлы карар, 2022 елның 26 октябрендәге карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесенең ул 12 688 сум тәшкил итүче вазыйфаи окладь күләменә тапкырлана.»;

3 пунктның 3 пунктчасында «ике процент» сүзләрен 15 процент сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «50 процентка кадәр күләмдә» сүзләрен «50 процент күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

1 пунктчада «8 процентка кадәр күләмдә» сүзләрен «8 процент күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) һөнәрләрне берләштергән, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән һәм үтәгән өчен айлык өстәмә түләү, үзенең төп вазыйфаларын вакытлыча

булмаган хезмәткәрләренең вазыйфалары белән беррәттән алып бару өчен - хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә гамәлдәге законнар нигезендә эш буенча айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә;

төнлә эшләгән өчен (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) - хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән күләмдә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен - икеләтә көнлек тариф ставкасы күләмендә;

хезмәт җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә нормалаштырылмаган эш көне өчен - айлык тариф ставкасының 10 проценты күләмендә;

7 пунктның 4 пунктчасында «ике процент» сүзләрен 15 процент сүзләренә алмаштырырга.

1 нче кушымта таблицасына «бүлек начальнигы урынбасары» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Сектор начальнигы | 1,5». |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе И.И. Гозәеров